# ХЫЯЛ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ
“ЧАЛМАНАРАТ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”НЕҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ


## Декабрь ае календаре



*3 нче декабрь-*
**Билгесез солдат көне**



*1 - 10 нчы декабрь* -
**инвалидлар ункөнлеге**




*12 декабрь* -
**Русия Конституциясе көне.**

## Яшь гражданнар



“Мин – Россия гражданины!” акциясе кысаларында Актанышта 14 яше тулган яшүсмерләргә тантаналы төстә паспортлар тапшырылды. Алар арасында мәктәбебездән Миләүшә Алмаз кызы Фазлыева, Рубин Рәмзис улы Гайсин да бар иде.

Гражданлык- ул кеше һәм дәүләт арасындагы торыклы сәяси һәм хокукый бәйләнеш.

Граждан булу файдалы Граждан булу дәрәҗә, горурлык.

**Гражданлык хокуклары:**

1. Яшәүгә хокук
2. Ирекккә һәм шәхси кагылгысызлыкка хокук
3. Торакның кагылгысызлыгына хокук
4. РФ территориясендә законлы рәвештә яшәгән һәркем өчен күченеп йөрү ирегенә һәм яшәү урынын сайлауга хокук.
5. Шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, язышу, телефоннан сөйләшү серенә хокук

**Яшүсмерләрнең бурычлары**

1. Гражданин салымнар, җыемнар түләргә тиеш.
2. Гражданин Ватанны сакларга тиеш.
3. Гражданин табигатьне сакларга тиеш.
4. Гражданин дәүләт законнарын үтәргә бурычлы
5. Гражданин балалар һәм хезмәткә сәләтсез әти- әнисе турында кайгыртырга тиеш.
6. Гражданин мәдәният һәйкәлләрен сакларга тиеш.

**Рус теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Раушания Сәйфулла кызы Галимжанова**



**“Парламент дәресе - 2017”конкурсында III урын**

**VIII класс укучысы**
**Диана Роберт кызы Акбулатова**



**Рус әдәбияты олимпиадасында район призёры**

**VII класс укучылары**
**Диана Рәис кызы Насертдинова һәм Илгизәр Вилдан улы Имамов**



**Районара Мөхәммәт Мәһдиев укуларының иҗади эшләр бәйгесендә III урын**

**VIII класс укучысы**
**Миләүшә Алмаз кызы Фазлыева**



**ГТО нормаларын тапшыруда Бронза медаль иясе**

**IX класс укучысы**
**Ильмир Нияз улы Локманов**



**Кышкы спорт Сезонын ачу I урын**

***Тырышлык турында мәкальләр***

**Маңгай тире эшнең сыйфатын яхшырта**
**Хезмәте каты - җимеше татлы**
**Булдыклы кеше таштан икмәк чыгарыр**

**Сәйдәш Шакиров, VIII класс укучысы**

# Биология укытучылары семинары

**VIII класста биологиядән ачык дәрес**



**Гөлнара Рафаэль кызы Әхметова уздырган дәрес күңелләрдә озак сакланыр**

**“Тамчы-шоу” да белемнәребезне сынадык**



**Алмазия Тәминдар кызы Рәхимова оештырган бәйгедән үзебезгә нәтиҗәләр ясадык**

Район бүлеге мөдире Әхмәтгалиева Зөлфия Вил кызы һәм килгән мөгаллимнәрнең укытучыларыбыз һәм безгә әйткән рәхмәт сүзләрен ишетү күңелләребезгә рәхәтлек индерде..

**Миләүшә Фазлыева, VIII класс укучысы**

# Хуш киләсең, Яңа ел!



## Яңа ел кичәсе

Яңа ел кичәсе башлангыч класс укучылары белән әзерләнгән бәйрәм-тамашасы уеннар, олимпиада һәм конкурсларда җиңгән укучыларны тәбрикләү белән үрелеп барды.

## Яңа елны кайда, ничек каршылыйлар?

**Русиядә** Яңа елны XV гасырга кадәр йә 1 марттан башланган, йә 1 сентябрьдән. XV гасырда исә Яңа елны 1 сентябрьдә каршылый башлаганнар. Петр I указы буенча, 1700 нче елда Яңа елны 1 нче гыйнварда каршы алалар. **Австралиядә -** 1 гыйнварда, **Индонезиягә** – октябрьдә, 1 гыйнварда **японнар** кояшны каршыларга урамга чыгалар һәм бер-берсенә бүләкләр бирешәләр.

**Ничек аңлатыр идегез?**

Елның иң соңгы уникенче ае - ул декабрь. Ә сез “декабрь”сузенең нәрсәне аңлатуын беләсезме? Ул грекча “дека”- “ун”дигәннән алынган: декалитр - ун литр, декада-ун көн һ.б. Димәк, декабрь ае “унынчы ай” булып чыга. Айның исеме җисеменә туры килми!

Рәсемнәрдә сурәтләнгән музыка уен коралларының исемнәрен башватыкычтан табыгыз. Бер сүз билгеләп куелган инде. Артып калган хәрефләрне буш шакмакларга дөрес язагыз, музыка белән бәйле профессия килеп чыгар.



| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | Г | К | Р | С | С | О | О | Я | Н |
| Т | И | С | И | А | К | Ф | Б | А | Б |
| А | Р | А | П | К | А | О | А | Р | А |
| М | К | К | Д | Е | О | Н | Б | А | П |
| Р | А | О | Р | О | Н | П | И | Н | З |
| О | Я | К | Л | Н | Е | Т | А | Н | И |
| И | Л | Ь | А | Р | Б | Ы | Т | О | Н |
| В | И | О | Н | Л | Ь | Р | К | У | Р |
| О | О | Л | Ч | Е | Р | Г | Ы | Й | А |

## *Котлыйбыз!*



Декабрь бураннары алып килгән
Яңа ел белән котлыйбыз!

Яңа ел бәхетле мизгелләр, матур вакыйгалар, яхшы хәбәрләр, саулык-сәламәтлек алып килсен. Эшегездә, укуыгызда зур уңышлар телибез.



«Хыял» Чалманарат төп гомуми белем бирү укучыларының фәнни-популяр, әдәби-нәфис айлык басмасы.
Шеф-мөхәррир: Диана Акбулатова Җаваплы сәркатип: Миләүшә Фазлыева Фотохәбәрче: Сәйдәш Шакиров
Безнең адрес: 423752, Чалманарат авылы, Мәктәп ур., 7 нче йорт. E-mail: Schal.Akt@edu.tatar.ru, chalm.akt@yandex.ru Тираж: 15 данә Кул куелды: 14.00; 23.12.2017
Мәктәп компьютерында басылды. Бәясе ирекле. Мәкаләдәге фикерләр өчен мөхәррият җавап тотмый.